КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 февраль г.Казань № 68

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Төбәк әһәмиятендәге «ВЛ 220 кВ Щелоков – Үзәк 1 һәм 2 чылбырлар» объектын төзү максатларында, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281статьялары, Россия Федерациясе Җир кодексының VII[1] бүлегенең 49 статьясы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Челтәр компаниясе» ААҖнең Югары Ослан муниципаль районында урнашкан, Җамалиев Р.Н милкендә булган, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шәле авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге 2,5 гектар мәйданлы җир кишәрлегеннән барлыкка килгән 16:33:170416:308 кадастр саны белән 0,1771 гектар мәйданлы җир кишәрлеген төбәк әһәмиятендәге «ВЛ 220 кВ Щелоков – Үзәк 1 һәм 2 чылбырлар» объектын төзү максатларында Челтәр компаниясе» ААҖ акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын расларга (теркәлгән).

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына урнаштырырга;

әлеге карарны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

әлеге карар күчермәләрен Р.Н.Җамалиевка, «Челтәр компаниясе» ААҖнә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән алына торган җир кишәрлегенә түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә «Челтәр компаниясе» ААҖ белән берлектә формалаштырылган җир кишәрлеген Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында килешү әзерләргә (алга таба – җир кишәрлеген алу турында килешү) һәм аны милекчегә җибәрергә.

4. «Челтәр компаниясе» ААҖнә тәкъдим итәргә:

алына торган җир кишәрлегенә мөнәсәбәттә, аның әлеге карар белән расланган урнашу схемасы нигезендә, кадастр эшләре үткәрергә;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләмен һәм мондый алу алып килә торган чыгымнар күләмен билгеләргә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә җир кишәрлеген алу турында килешү чараларын үткәрү һәм аны имза кую өчен алына торган җир кишәрлегенең хокук иясенә җибәрергә;

җир кишәрлеген алу турында килешү төзергә;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләргә;

алына торган җир кишәрлегенә «Челтәр компаниясе» ААҖ милек хокукын дәүләт теркәвенә алырга;

алына торган җир кишәрлегенең хокук иясе имзаланган җир кишәрлеген алу турында килешүне бирмәгән очракта законда билгеләнгән вакытта судка тиешле шикаятьләр бирергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин